5.8.1. — Общая педагогика, история педагогики и образования
**Ссылка для цитирования:**
Хабибрахманова Р. Н. Һөнәри белем бирүче уку йортларында “Туган телдә әдәбият” укыту барышында кейс технолгиясен куллану // Современное образование: актуальные вопросы и инновации. 2024. № 4 (23).
URL: http://irortsmi.ru/wp-content/uploads/2024/12/2024_4_khabibrakhmanova.pdf

УДК 378

**Резеда Накифовна Хабибрахманова**
Һөнәри белем биру бүлеге фәнни хезмәткәре, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, Казан

# Һөнәри белем бирүче уку йортларында “Туган телдә әдәбият” укыту барышында кейс технолгиясен куллану

***Аннотация.*** Әлеге мәкаләдә һөнәри белем бирүче уку йортларында әдәбият укытуда кейс технологиясе кулланып укыту, аның уңай нәтиҗәләре турында сүз алып барыла.
***Төп сүзләр:*** һөнәри белем, технология, кейс технологиясе, уку-укыту, студент, укытучы, дәрес, әдәбият, әсәр

**Rezeda N. Khabibrakhmanova**
Research Associate, Vocational Education Development Department, Institute of Education Development of the Republic of Tatarstan, Kazan, Russia

# Application of Case Technology in Educational Institutions of Professional Education in Teaching «Literature in the Native Language»

***Abstract.*** This article discusses case technologies for teaching literature in professional educational institutions, its positive results. The positive aspects of this technology will be touched upon in the teaching of literature.
***Keywords:*** vocational education, technology, case technology, training, student, teacher, lesson, literature, work

Бүгенге көндә урта һөнәри белем бирү системасында укытуның нәтиҗәле ысулларын һәм чараларын эзләү, камилләштерү һәм куллану актуаль бурыч булып тора. Чөнки, замана яшь белгечләр алдына күпкырлы максат, бурычлар куя: син үз эшеңнен остасы гына түгел, ә бәлки купкырлы белгеч булып, тормышта үз белемнәреңне тиешле урында куллана алуны да таләп итә. Шуның белән бәйле рәвештә, укытучы алдына куелган бурычлар да үзгәрә бара. Укытучы укыту барышында студентларның мөстәкыйль эшчәнлеген оештырырга, шул вакытта студентның үз фикерен белдерә алу сәләтен дә ачарга тиеш.

Заманча белем бирү практикасында уку материалын уңышлы үзләштерүне тәэмин итә торган күпсанлы алымнар һәм методлар бар. Шулар арасында кейс-технология бигрәк тә популярлаша бара.

Т.С. Терновская фикеренчә, кейс ул ниндидер вакыйга турында сөйли торган, конкрет практик ситуация [1, с. 4]. Конкрет ситуацияләр методы нигезендә имитацион модельләштерү, башкача әйткәндә, әлеге методны укыту барышында куллану, реаль һөнәри эшчәнлек ситуациясе тасвирламасы белән, конкрет мисал яисә әзер материаллардан файдалану күздә тотыла. Әлеге техноло-

© Хабибрахманова Р. Н., 2024

гия укучыларда алга таба һөнәри эшчәнлектә дә кирәкле булган бик мөһим интеллектуаль күнекмәләрне үстерергә мөмкинлек бирә [2, с. 138].

Кейс-технология — белем бирүнең интерактив технологиясе, реаль яисә уйлап чыгарылган ситуацияләр нигезендә, белемнәрне үзләштерүгә генә түгел, студентларда яңа сыйфатлар һәм белем формалаштыруга да юнәлдерелгән. Аның төп бурычы – проблемалы сорау кую һәм аларны хәл итү сәләтен үстерү, мәгълүмат белән эшләргә өйрәнү. Шул ук вакытта студентны әзер белем алуга түгел, ә аны табуга, укытучының һәм студентның иҗат эшчәнлегенә дә игътибар бирелә.

Кейслар технологиясен кулланып эшләү — студентларга мәгълүмат белән эшләү процессында эзлекле рәвештә танып белү операцияләрен үзләштерергә мөмкинлек бирә торган бурычларны үти: танышу — аңлау — куллану — анализ — синтез — бәяләү.

Кейс-технологияләрен куллану өчен иң уңайлы дәресләр — әдәбият укыту дәресләре булып тора, чөнки нәкъ менә әлеге дәресләрдә, текст белән эшләгәндә, студентларга теге яки бу фикергә килергә ярдәм итәлә.

Кейс технологиясе кулланып уздырылган дәресләр интеграцияләргә мөмкинлек бирә, чөнки әдәбият еш кына тарих, психология һәм социология белән бәйләнештә. Мәсәлән, әдәби әсәрне анализлау аның тарихи контекстына кагыла ала, бу исә студентларга текстны гына түгел, ул барлыкка килгән чорны да тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә. Шул рәвешле, әдәби кейслар белем бирү чарасы гына түгел, социаль-мәдәни мәсьәләләр турында дискуссияләр өчен мәйданчык та була.

Әдәбият дәресләренә кейслар төзү өчен, укытучыдан өйрәнелә торган әсәрнең һәм дәрес уздырыла торган группаның үзенчәлекләрен белү таләп ителә. Әлеге эштә иң беренче адым булып, кейс-технологияне куллану аша ирешергә мөмкин булган белем бирү максатларын һәм бурычларын билгеләү тора. Кейслар текстны анализлауны тирәнәйтүне,аның сюжет һәм тематик үзенчәлеген аңлауны да таләп итә.

Һөнәри белем бирүче уку йортларында әдәбият укыту дәресләрендә түбәндәге формадагы кейсларны кулланырга була:

1. Студентларга классик татар әдәбияты геройларыннан берсенең (мәсәлән, Гаяз Исхакыйның «Остазбикә) хәзерге чынбарлыкка туры килүен күз алдына китерергә тәкъдим ителә. Алар бу персонажның хәзерге шартларга ничек җайлашуын, аңа нинди сынауларны җиңәргә туры килүен һәм аның карашлары һәм гамәлләренең ничек үзгәрүен тасвирларга тиеш.

Эш барышы:

- Студентлар әдәби персонажларның берсен сайлыйлар һәм аның характерын һәм тормыш шартларын җентекләп өйрәнәләр.
- Аннары алар хәзерге заман социаль, сәяси һәм мәдәни чынбарлыкны исәпкә алып, бу персонажның безнең заманда ничек яши алуын күз алдына китерәләр.
- Студентлар үз персонажларының ничек үзгәрүен һәм аңа нинди яңа сынаулар узарга туры килүен тасвирлый торган презентацияләр әзерлиләр.
- Дәрестә тәкъдир итүләр үткәрелә, анда студентлар үзләренең идеяләре һәм фикерләре белән уртаклашалар.

2. Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» драмасында балалар һәм ата-аналар арасындагы мөнәсәбәтләрнең катлаулылыгының сәбәпләрен ачыкларга тәкъдим ителә.

Эш барышы:

- Студентлар драманы укый һәм әсәрдәге төп герой өчен сайлау авыр булган моментларны аерып чыгара.
- Студентлар төркемнәргә бүленәләр һәм герой гамәлләренең мөмкин булган вариантлары турында фикер алышалар, аларның һәрберсен дәлилләп бирәләр
- Фикер алышканнан соң һәр төркем үз карарын группа алдында тәкъдим итә, һәм ни өчен бу вариантны сайлап алуын аңлата.
- Йомгаклау дискуссиясе үткәрелә, анда студентлар проблемаларны хәл итүнең төрле алымнарын чагыштыралар һәм үз фикерләрен әйтәләр.

Кейс технолгиясе кулланып уздырылган дәресләр, уку сыйфатын гына яхшырып калмый, ә студентлар өчен олы тормышта кирәк булган компетенциялэр формалаштырырга да ярдәм итә. Кейсны уңышлы файдалану нигезендә алынган нәтиҗәләр күрсәткәнчә, әлеге метод укытуның сыйфатын арттырырга гына түгел, укучыларда аларның киләчәк карьерасы өчен кирәкле һөнәри компетенцияләр формалаштырырга да ярдәм итә.

Кулланылган әдәбият
1. Даутова О.Б., Иваньшина Е.В., Казачкова Т.Б. и др. Современные педагогические технологии основной школы в условиях. СПб: КАРО, 2015. 176 с.
2. Даутова О.Б., Крылова О.Н. Педагогические технологии для старшей школы в условиях цифровизации современного образования: учебно-метод. пособие для учителей. — СПб.: КАРО, 2020. — 176 с.
3. Шахбанова П.Г. Кейс-технологиии как один из инновационных методов на уроках русского языка и литературы // Международный школьный научный вестник. 2022. № 6.
4. Долгоруков А.М. Метод case-study как современная технология профессионально-ориентированного обучения // Корни. URL: https://evolkov.net/case/case.study.html (дата обращения: 15.12.2024).

References
1. Dautova OB, Ivan’shina EV, Kazachkova TB, et al. *Sovremennye pedagogicheskie tekhnologii osnovnoi shkoly v usloviyakh=Modern pedagogical technologies of the basic school in the conditions.* St. Petersburg: KARO Publ., 2015. 176 p. (In Russ.)
2. Dautova OB, Krylova ON. *Pedagogicheskie tekhnologii dlya starshei shkoly v usloviyakh tsifrovizatsii sovremennogo obrazovaniya=Pedagogical technologies for high school in the context of digitalization of modern education*. St. Petersburg: KARO Publ., 2020. 176 p. (In Russ.)
3. Shakhbanova PG. Keis-tekhnologiii kak odin iz innovatsionnykh metodov na urokakh russkogo yazyka i literatury=Case technologies as one of the innovative methods in Russian language and literature lessons. *Mezhdunarodnyi shkol’nyi nauchnyi vestnik.* 2022;(6). (In Russ.)
4. Dolgorukov AM. Metod case-study kak sovremennaya tekhnologiya professional’no-orientirovannogo obucheniya. In: Korni=Roots. (In Russ.) URL: https://evolkov.net/case/case.study.html [Accessed 15 December 2024].